УДК 81′1

***Э.Х. Кадирова***

# ЛӘЙЛӘ МӘХМҮТОВА – ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕ ТАРИХЫНДА ТИРӘН ЭЗ КАЛДЫРГАН ШӘХЕС

В научном наследии Лейли Тагировны Махмутовой, представленном трудами по грамматике, лексике и фразеологии современного татарского литературного языка, исторической диалектологии татарского языка, татарской лексикографии, татарской диалектологии, особое место занимает западный диалект татарского языка. В данной статье описывается ее научная деятельность и вклад в развитие диалектологии.

**Ключевые слова:** лингвистическая персонология, татарское языкознание, татарская диалектология, диалектная лексикография, Лейла Тагировна Махмутова.

In the scientific heritage of Leyli Tagirovna Makhmutova represented by works on grammar, vocabulary and phraseology of the modern Tatar literary language, historical dialectology of the Tatar language, Tatar lexicography, Tatar dialectology, a special place is occupied by the Western dialect of the Tatar language. This article describes her scientific activities and contributions to the development of dialectology.

**Keywords:** linguistic personology, Tatar linguistics, Tatar dialectology, dialect lexicography, Leila Tagirovna Makhmutova.

Үзенә кадәр эшләгән билгеле галимнәрнең хезмәтен лаеклы дәвам итеп, татар тел белеме фәнен яңа югарылыкка күтәргән, 25 ел дәвамында ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (сәнгать) институтының күп тармаклы, иң эре тел секторын җитәкләгән, төрки диалектология өлкәсендә СССР күләмендә танылу алган, 150 гә якын фәнни хезмәт авторы, филология фәннәре кандидаты Ләйлә Мәхмүтова – татар тел белеме тарихында уникаль, тирән эз калдырган шәхес.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова 1925 елның 25 августында Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы Муса авылында үз чорының актив җәмәгать эшлеклесе Таһир ага Мәхмүтов гаиләсендә дөньяга килә. Таһир ага укымышлылар нәселеннән. Аның әтисе Хәбибулла агай ике тапкыр Мәккәгә һәм Мәдинәгә хаҗ кыла. Беренче тапкыр – 17 яшендә. Хаҗдан кайтканда, ул Төркиядә туктала һәм, балдакларга язу төшереп акча эшләп, шул якларда сәяхәт кыла. Хәбибулла 35 яшендә туган авылына кайта һәм өйләнә. Ләйләнең әтисе Мөхәммәдтаһир гаиләдә унберенче бала була. Хәбибулла бабай малайларның берсен шәһәргә укырга җибәрсә, икенчесен авылда калдыра. Мөхәммәдтаһиргa Казанда белем алу бәхете тия. Ул Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлый, Казанда кала. Мөхәммәдтаһир язучылар белән аралаша: Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов белән таныш була,

«Әлислах» газетасы редакциясендә эшли. Баштарак начар почерклы язучыларның әсәрләрен күчереп язу белән шөгыльләнсә, соңрак үзе дә авыл хуҗалыгын популярлаштыру юнәлешендә мәкаләләр бастыра. Мөхәммәдтаһир Санкт-Петербург педагогика институтында читтән торып укый һәм рус-татар мәктәбе укытучысы белгечлеген ала. Ул Казанда атаклы сәнәгатьчеләр нәселеннән булган Нәгыймә Әхсән кызы Аитова белән танышып гаилә кора. Укымышлы, гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән шәһәр кызы сөйгәне белән ерак бер авылга китеп бара. Бер-бер артлы 5 балалары туа. Бу елларда ире күрше авылларда укыта. Соңыннан гаилә Хвалын шәһәренә күченә. Биредә Таһир Мәхмүтов рус-татар башлангыч мәктәбен ачуга ирешә һәм пенсиягә чыкканчы анда эшли. Шәһәрдәге татарлар үз балаларын бу мәктәпкә башлангыч белем алырга җибәргәннәр. Бу Т. Мәхмүтовның педагогик осталыгы турында сөйли. Мәхмүтовлар гаиләдә татарча гына сөйләшәләр. Гаиләдәге туган телгә, туган әдәбиятка мөнәсәбәт нәкъ менә шул вакытларда ук кызда татар телен тирәнтен өйрәнүгә омтылыш уяткан булса кирәк.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң Ләйлә Ленинград дәүләт университетының Көнчыгыш телләр факультетына укырга керә. Студент вакытында ук нык кызыксынучан Ләйлә Мәхмүтовага университетта Н.К. Дмитриев, С.Е. Малов, А.Н. Кононов, А.К. Боровков, В.М. Жирмунский кебек атаклы тюрколог-галимнәр белем бирә. Моннан тыш ул факультатив рәвештә гарәп теле һәм иранистика буенча академик И.Ю. Крачковский укыган лекцияләргә, СССР Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы А.Ю. Якубовскийның Якын һәм Урта Көнчыгыш мәсьәләләре буенча махсус курсларына йөри. Ләйлә уку барышында Сталин стипендиясе ала. Ул 1948 елда университетны кызыл дипломга тәмамлый һәм 1948–1952 елларда аспирантурада белем ала.

Ләйлә Мәхмүтова 1952 елда (вакытыннан алда) «Татар теленең касыйм сөйләше үзенчәлекләре» («Особенности касимовского говора татарского языка») темасына кандидатлык диссертациясен яклый. Бу хезмәт сөйләшләрне өйрәнүгә багышланган тикшеренүләрнең калыбы буларак бәяләнә. Аның зур күләмле, тирән эчтәлекле мәкаләләрендә һәм диссертациясендә әлеге тарихи яктан үзенчәлекле сөйләшкә караган уникаль лексик һәм фонетик тел материалы урын ала.

1952 елда Ләйлә Мәхмүтова Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына (1998 елдан – Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшкә урнаша. Яшь булуга да карамастан, кызыксынучан, талантлы, тирән белемле, эзләнүчән Ләйлә Таһир кызы диалектология юнәлешендә тикшеренүләрен дәвам итә. Институтта ул башта – кече фәнни хезмәткәр, 1959 елдан өлкән фәнни хезмәткәр була. 1961 елның беренче июненнән Институтта тел секторының җитәкчесе итеп билгеләнә һәм лаеклы ялга (1986 елның 31 мае) киткәнгә кадәр шул вазифаны башкара.

Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтованың фәнни эшчәнлеге киңкырлы. Татар диалектологиясе, лексикографиясе, лексикологиясе, тарихи

диалектология, татар теле тарихы өлкәләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимәнең фәнни мирасында татар сөйләшләре аерым урын алып тора. Ул аларны өйрәнүгә кырык елга якын гомерен багышлый. Диалектологиянең татар тел белеменең мөстәкыйль тармагы дәрәҗәсенә күтәрелүендә Ләйлә Мәхмүтованың өлеше бик зур. 1960–1970 елларда Ләйлә Таһир кызы мөдирлек иткән тел секторының берничә хезмәткәреннән торган төркем киң территориядә таралган татар сөйләшләрен җентекләп өйрәнүгә керешә. 1954–1957 елларда Ләйлә Мәхмүтова җитәкчелегендә Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарына берничә экспедиция оештырыла. Л.Т. Мәхмүтова җыелган материалларга һәм архив чыганакларына нигезләнеп, үзенең «О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиции 1954–57 гг.)» исемле күләмле мәкаләсен бастыра [Махмутова, 1962]. Ул анда бу төбәктә яшәүчеләрнең теле татар әдәби теленә бик якын булуын ассызыклый. Автор, татар диалектологлары арасында беренче булып, «башкорт», «типтәр», «мишәр» этнонимнарын тарихи-лингвистик яктан өйрәнү зарурлыгын ассызыклый.

Галимәнең күпсанлы мәкаләләрендә татар сөйләшләренә нисбәтле кыйммәтле материаллар, кызыклы фактлар урын ала һәм алар татар тел белемендә, татар диалектологиясендә булган аерым мәсьәләләрне ачыклауда зур әһәмияткә ия. Аның күп мәкаләләре көнбатыш диалект сөйләшләрен өйрәнүгә карый. «Краткие заметки о хвалынском говоре мишарского диалекта татарского языка» (1966), «К монофтингизации дифтонгов в мишарском диалекте татарского языка» (1973), «Некоторые наблюдения над лексикой мишарских говоров (к мишарско-мордовским заимствованиям)» (1976), «Формы прошедшего времени в мишарском диалекте татарского языка» (1976), «О характере и некоторых типах русских заимствований в мишарском диалекте татарского языка» (1978), «Некоторые материалы по лексике мишарского диалекта татарского языка (тюркский пласт)» (1979), шулай ук озак еллар бергә эшләгән хезмәттәше Наҗия Борһан кызы Борһанова белән берлектә язылган «К вопросу об истории образования татарских диалектов и говоров» (1962), «О диалектном членении татарского языка» (1962), «Диалекты татарского языка» (2010) мәкаләләрендә сөйләшләрне бүлү һәм классификацияләүнең теоретик мәсьәләләре, аларны тикшерү һәм тасвирлау методлары, диалект материалларын фәнни шәрехләү принциплары карала, шулай ук сөйләшләрне чагыштырып анализлау ысуллары, комплекслы якын килү (ягъни анализлау вакытында башка чиктәш фәннәр буенча мәгълүматларны да куллану) мөмкинлекләре өйрәнелә.

Галимә тарихи аспектта телне һәм шул телдә сөйләшүчеләрне (носители языка) өйрәнүдә диалектларга мөрәҗәгать итүнең әһәмиятен һәрдаим ассызыклый. Кызганыч, татар язма истәлекләренең күпчелек өлеше безнең көннәргә кадәр килеп җитми. Л. Мәхмүтова моны билгеләп, диалектологик мәгълүматларның шушы шартларда

сөйләм теле һәм аның язма әдәби варианты тарихын өйрәнүдә мөһим чыганак булуын әйтә. Галимә тарихи чыганаклар аша тел (бигрәк тә аның диалектлары) үсешен күзәтү мөмкинлеген «Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики: краткий анализ и приложение» [Махмутова, 1982], «О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики)» [Махмутова, 1985, с. 117–142] кебек зур күләмле мәкаләләрендә ача. Ул аларда кыпчак (Codex Cumanicus буенча) һәм татар телләре арасындагы фонетика һәм грамматика өлкәләренә караган охшашлыкларны анализлый.

Экспедиция материалларына нигезләнеп язылган мәкаләләр (кереш характерындагы мәкаләләр, тикшеренү мәкаләләре, текстлардан үрнәкләр) арасында Л.Т. Мәхмүтованың Н.Б. Борһанова белән берлектә язылган «К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров» хезмәтендә урта һәм көнбатыш диалектларны өйрәнү тарихы, әлеге ике диалектның фонетика, морфология өлкәләрендә дифференциаль билгеләре китерелә. Мәкаләдә Казанда үткәрелә торган диалектологик өйрәнүләргә куелган теоретик таләпләр дә урын ала. Шул ук җыентыктагы «Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области» [Махмутова, 1962] дигән тирән эчтәлекле мәкаләдә бу төбәктә яшәгән татарларның теленә караган үзенчәлекләр тупланган материалларның телен ачык күзалларга мөмкинлек бирә. Автор әлеге мәкаләсендә экспедицияләрдә тупланган бай тел материалын фәнни тасвирлау бурычын куя. Анда сөйләшнең фонетик һәм морфологик үзенчәлекләренә зур урын бирелә. Төрки телләр буенча күренекле галим, филология фәннәре докторы Ә.Р.Тенишев бу җыентыкларга язган рецензиясендә Казанда диалектологик тикшеренүләрнең киң колач белән үсүен ассызыклый, хезмәттәге барлык мәкаләләргә карата үз фикерен белдерә, аларны югары бәяли. Пенза өлкәсендә туып үскән галимә Л.Т. Мәхмүтованың җыентыктагы 37 битлек «Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области» мәкаләсенә тәфсилле анализ ясый, ә «Некоторые наблюдения над лексикой касимовского говора татарского языка» мәкаләсендә [Махмутова, 1962] «яңа лексик материал китерелгәнлеген һәм аның диалектологик сүзлек өчен кыйммәтле чыганак булуын» әйтә [Тенишев, 2006, с. 68].

Барлык төрки телләр диалектларының лексик һәм фонетик-грамматик төзелешен бер юнәлештә тикшерүнең аерым әһәмиятен исәпкә алып, Тюркологлар комитеты төрки телләр диалектларын өйрәнүнең кыскача схемасын эшләүне Л.Т. Мәхмүтовага йөкли. Авторның әлеге хезмәте («Краткая схема описания тюркских диалектов») «Советская тюркология» журналында басылып чыга [Махмутова, 1983].

Л.Т. Мәхмүтованың 1978 елда Мәскәүдә «Фән» нәшриятында басылган «Опыт исследования тюркских диалектов: мишарский диалект татарского языка» монографиясе – аның капиталь хезмәте

[Махмутова, 1978] һәм ул классик тикшеренү статусына ия. Китапта, күп кенә тарихи һәм архив чыганаклары аша, көнбатыш диалект вәкилләрен күчереп утырту юнәлешләре, авылларның килеп чыгышы турында, аларның элек яшәгән урыннарда калган татарлар белән генетик бәйләнешләре хакында фикерләр урын ала. Автор аларны үзе туплаган тел материаллары белән үреп бирә. Галимә көнбатыш диалектның фонетикасы һәм морфологиясен татар әдәби теле белән чагыштырып, тирәнтен анализлый. Өстәмә чагыштырма материал сыйфатында башка кардәш һәм хәтта кардәш булмаган телләрдән дә мәгълүматлар җәлеп ителә. Хезмәткә галимнәр тарафыннан бүген дә югары бәя бирелә.

Ләйлә Мәхмүтова татар диалектологиясе ирешкән уңышларны популярлаштыру, киң масса укучыларга җиткерү эшенә дә сизелерлек өлеш кертә. Галимә – «Татар диалектологиясе буенча материаллар» дип аталган 9 томлы хезмәтнең (1955, 1962, 1974, 1976, 1978, 1983, 1988, 1989, 1990) редакторы һәм төзүчесе. Тупланган материалның киңлеге һәм күптөрлелеге безгә татар авылларында яшәгән буынның тере сөйләмен җиткерә, аларның дөнья картинасын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә, чөнки анда халыкның традицион тамашалары, милли стереотиплар, иске көнкүреш детальләре һәм шул еллар крестьян тормышы чынбарлыгы үзенчәлекле үрелеп бара. Бу хезмәтләр диалект системасының фонетик, грамматик һәм лексик үзенчәлекләре күзлегеннән генә түгел, бәлки XX гасырның икенче яртысында татар авылы кешесенең тел шәхесе (Языковая личность сельского жителя) үзенчәлекләрен реаль гәүдәләндерү буларак та, тикшеренүчеләр тарафыннан укыла, укылыр һәм интерпретацияләнер.

1955, 1962 елларда Л.Т. Мәхмүтова тырышлыгы белән Татарстаннан читтә (Пенза, Самара, Киров өлкәләрендә, Мордовия, Удмуртия, Башкортстанда) киң таралган татар сөйләшләрен җентекләп өйрәнеп язылган мәкаләләрдән торган «Татар диалектологиясе буенча материаллар»ның беренче һәм икенче китаплары дөнья күрә.

Болардан тыш Л.Т. Мәхмүтова «Татар теленең тарихи диалектологиясе буенча тикшеренүләр» (1979, 1982, 1985) һәм күп кенә башка фәнни җыентыкларны редакцияләп басмага әзерли.

Галимнәр Л.Т. Мәхмүтова тел секторы белән җитәкчелек иткән елларны «татар диалектологиясе үсеш-үзгәрешенең иң уңышлы чоры»дип саныйлар [Рамазанова, 2014, б. 37]. Бу этапта Идел-Урал регионы татар сөйләшләренең атласын төзү һәм аны матбугатка әзерләү көнүзәк мәсьәлә булып тора. Ләйлә Мәхмүтова оештырган һәм җитәкчелек иткән күпсанлы диалектологик экспедицияләр барышында СССР халыклары арасыннан беренчеләрдән булып, диалектологик Атлас өчен материал туплана. Ләйлә Мәхмүтова – 845 авылның тел мәгълүматларын чагылдырган ике томлык «Урта Идел һәм Урал буе татар сөйләшләре Атласы»ның фәнни җитәкчесе, баш мөхәррире; «Атласка шәрехләр...»нең җитәкчесе, авторларының берсе; «Атлас...»ның Программасын төзүчеләрнең берсе, принципларын

эшләүче. «Атласка» кереш мәкалә авторларының берсе дә – Ләйлә Таһир кызы.

Л. Мәхмүтова – барыннан да бигрәк атаклы диалектолог галимә. Әмма аның лексикография, тел тарихы, лексикология тармакларындагы фәнни хезмәтләре дә татар тел белемендә лаеклы урынын тапты.

Ләйлә Таһир кызы җитәкчелегендә, фәнни редакторлыгында бастырылган, ул төзүче буларак катнашкан сүзлекләрнең саны бихисап: дүрт (1955–1959) һәм бер томлы (1969; 1971; 1984; 1985; 1991 һ.б.) «Русско-татарский словарь»; «Татар теленең фразеологик сүзлеге» (1957; 1959); «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (1948; 1953; 1958); «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (1969); өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1977–1981) һ.б.

Филология фәннәре кандидаты Л.Т. Мәхмүтова Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИдә эшләп, татар диалектологларының бер генә буынын тәрбияләмәгән. Л.Т. Мәхмүтова бирелдә үз эшенә бирелгән диалектологлар коллективын төзи алды. Аларның күбесе татар диалектологиясе өлкәсендә билгеле галимнәр булып танылды. Л. Мәхмүтова нигезләгән, өйрәнгән фәнни принциплар аның дәвамчылары, филология фәннәре докторлары Л.Ш. Арсланов, Ф.С. Баязитова, Ф.Й. Йосыпов, Д.Б. Рамазанова, филология фәннәре кандидатлары Т.Х. Хәйретдинова, З.Р. Садыйкова, Р.Р. Шәмгунова хезмәтләрендә тагын да киңрәк ачыла.

Л.Т. Мәхмүтованың фәнни мирасы төрле буын тикшеренүчеләре өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә булып тора.

**Әдәбият**

*Бурганова Н.Б., Махмутова Л.Т.* К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 7–18.

Махмутова Лейля Тагировна // Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 218–221.

*Махмутова Л.Т.* Особенности касимовского говора татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Ленинградский госуниверситет. Ленинград, 1952. 10 с.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 125–162.

*Махмутова Л.Т.* О татарских говорах северо-западных районов Башкирской АССР (по материалам экспедиции 1954–57 гг.) // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 57–85.

*Махмутова Л.Т.* Некоторые наблюдения над лексикой касимовского говора татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 223–235.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов: мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 270 с.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики: краткий анализ и приложе-

ние // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 2. Казань, 1982. С. 68–153.

*Махмутова Л.Т.* О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 3. Казань, 1985. С. 117–142.

*Рамазанова Д.* Сүзләр дәрьясында йөзгән Ләйлә: [күренекле галимә Ләйлә Мәхмүтовага 75 яшь] // Ватаным Татарстан. 2000. 19 авг.

*Рамазанова Д.Б.* Заман белән бергә // Фәнни Татарстан. 2014. № 4. Б. 35–48.

*Тенишев Э.Р.* Материалы по татарской диалектологии // Избранные труды. Книга вторая. Уфа: Гилем, 2006. С. 65–75.

***Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*